# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

**(V чакырылыш)**

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

**КАРАРЫ**

7 июнь 2026 ел № 20

Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.10.2021 ел, №82 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы, 06.10.2003 № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 №248-ФЗ Федераль законы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 26.12.2008 ел, №294-ФЗ Федераль законы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы Татарстан Республикасының 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ санлы Законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.10.2021 ел, №82 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә (алга таба — нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.1 бүлегенең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылучы затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый. Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында контрольдә тотылучы затка ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә.”;

1.2. Нигезләмәнең 2.1 бүлегендәге 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Әгәр йөкләмәдә контроль төре һәм (яисә) контрольдә тотылучы затлар исемлеге күрсәтелмәгән булса, мондый йөкләмәне үтәүне оештыру максатларында әлеге бүлекнең 7 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары йөкләмәсе кабул ителә.»;

1.3. Нигезләмәнең 2.2 бүлегенә 4 пунктта түбәндәге редакциядәге 5 пунктча өстәргә:

«5. контрольдә тотылучы зат әлеге бүлекнең 1 пунктында каралган критерийларга туры килми.»

1.4. Нигезләмәнең 2.1 бүлегендәге 1 өлешенең 4 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган төбәк-төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә, федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә һәм муниципаль контроль төрләренә карата;

1.5. Нигезләмәнең 2.1 бүлегенең 1 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм «муниципаль контрольне» гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәр биргән контрольдә тотылучы затларга яисә белешмәләре классификацияләнгән чаралар реестрына кертелгән контрольдә тотылучы затларга карата урнаштыру. Мондый хәбәрнамәләр тапшырыла торган эшкуарлык эшчәнлеге төрләре исемлеге контроль төре турындагы нигезләмә белән расланa. Күрсәтелгән очракта мәҗбүри профилактик визит мондый хәбәрнамә тапшырылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча үткәрелә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы Район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин